ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» апрель 2022 ел № 93

«Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 237 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Хокук мониторингы нәтиҗәләре буенча муниципаль норматив хокукый актны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясына, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 408-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законга туТатарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 237 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:ры китерү максатларында, Әгерҗе районы прокуратурасының «Муниципаль норматив-хокукый актларга - «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 237 номерлы карарына» үзгәрешләр кертү кирәклеге турында» 2022 елның 06 апрелендәге 02-01-18-2022 номерлы мәгълүматын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 237 номерлы карарына кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
25.04.2022 № 93
карары белән расланган

**«Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 237 номерлы карарына үзгәрешләр**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 237 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.5 пунктының 4.1 пунктчасында түбәндәге сүзләр өстәргә::
«, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта;»;

2) 1.5 пунктының 7 (төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителми) абзацын түбәндәге эчтәлекле 4.2 пунктчасы белән тулыландырырга:
«4.2) индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү («күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш)»;

3) 2.5.1 пунктының 6 пунктчасына, 1 нче кушымтаның 3 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:
«, блокланган төзелеш йортларының берсен реконструкцияләгән очракта бер рәттә барлык йортларның да хокук ияләренең ризалыгы;».